**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "БОЛГАР ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№ 50-1** **«17» июнь 2025 ел**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының “Болгар шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының “Болгар шәһәре” муниципаль берәмлеге Советы

карар итте:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны 2025 елның 20 июнендә «Новая жизнь»-«Яңа томыш» газетасында, ТР Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә халыкка чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районының
"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы К.А.Молодов